Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге Советының
кырык беренче утырыш дүртенче чакырылыш
КАРАРЫ

31 гыйнвар, 2025 ел. № 112

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге башлыгы,
муниципаль хезмәткәрләренең
айлык акчалата бүләкләү күләмен
арттыру турында

"Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары нигезендә,
Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге Советының 2021 елның 9 апрелендәге 18 номерлы карарына "Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлеге башлыгы һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында" (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге Советының 2022 елның 29 декабрендәге 59 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) (алга таба-Карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
   1.1. 1.1 подпунктта 1 пунктның "19991" санын "20 991" санына алмаштырырга;
   1.2. 1.2 подпунктта 1 пунктның "13 323" санын "13 990" санына алмаштырырга.
2. Әлеге Карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.
3. Әлеге Карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге Карар 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге башлыгы И.Р. Ахметзянов